РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 2 сентябре** **Чистай шәһәре** **№16/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестицион проектлар буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестицион проектлар буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 5/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Муниципаль гарантиядән килеп чыга торган йөкләмәләр, муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән принципалда булган йөкләмәләр суммасында, ләкин муниципаль гарантия суммасыннан артмыйча, муниципаль бурыч

составына кертелә. Муниципаль гарантия бирү һәм үтәү муниципаль бурыч кенәгәсендә чагылырга тиеш.».

2. Әлеге карарның үз гамәлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратуын билгеләргә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны даими депутат комиссиясенә законлылык, хокук тәртибе, депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә (О.В. Добронавова) йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов